| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

№ 63/о

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

« 16 » 06 2022

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау хакында

«Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 313 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килү-килмәве турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын (кушымтада бирелә) расларга.

2. Билгеләргә:

стационар яки вакытлыча торак урыннарын мәҗбүри рәвештә биреп, имин районнарга вакытлыча күчерүдә булышлык күрсәтү буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында

бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен торак шартларын яхшырту буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү бүлеге күрсәтә;

торак йортлардагы урыннарны катлаулы авырулардан интегүче, аз хәрәкәтле гражданнар өчен җайлаштыру чараларын уздыру буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен Торак-коммуналь хуҗалык идарәсенең торак фонды объектларын эксплуатацияләү һәм территорияләрне төзекләндерү бүлеге күрсәтә.

3. Юридик бүлеккә (Э.Ю.Латыйпова), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Ж. Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 августындагы 130/о номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.М.Айзатуллин

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ
Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык
министрлыгының 2022 елның 16
июнендәге 63/о номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып «Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы $2^2$ пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар, коммерциясез оешмалар) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр (алга таба – бәяләмә) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык)

Стационар яки вакытлыча торак урыннарын мәҗбүри рәвештә биреп, имин районнарга вакытлыча күчерүдә булышлык күрсәтү буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында

бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүче – Торак шартларын яхшырту буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү бүлеге (алга таба – Бүлек).

Торак йортлардагы урыннарны катлаулы авырулардан интегүче, аз хәрәкәтле гражданнар өчен җайлаштыру чараларын уздыру буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүче – Торак-коммуналь хуҗалык идарәсенең торак фонды объектларын эксплуатацияләү һәм территорияләрне төзекләндерү бүлеге (алга таба – Бүлек).

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) бәяләмә;

2) бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү (әлеге Регламентка 2 нче кушымта).

Бәяләмә һәм бәяләмә бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән белдерү Министрлык бланкында рәсмиләштерелә, билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе Татарстан Республикасының нинди дә булса дәүләт мәгълүмат системасында теркәлми.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яки почта аша юллап; электрон почта адресы буенча һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) электрон документ рәвешендә.

2.3.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы.

Дәүләт хезмәтен кәгазьдә күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен мөрәҗәгать итүче Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң 30 көнлек чорда күрсәтелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталындагы шәхси кабинеты аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Республика порталындагы шәхси кабинетта күренә торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы беркетелгән көннән соң 30 көнлек чорда күрсәтелә.

Әлеге срок, Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциясез оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтә торган

затлар реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүче буларак тану турында карар кабул итү кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 6 пункты нигезендә рәсми мөрәҗәгатьләр юлланган очракта, озайтылырга мөмкин, ләкин иң күбе 30 көнгә кадәр генә.

Әлеге карарны кабул итү вакытын арттыру турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә гариза Министрлыкка алынган көннән башлап 30 көн эчендә хәбәр итә.

2.4.3. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

2.4.4. Рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулыннан (почта буенча, электрон адреска, факс аша, электрон документ рәвешендә) файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Министрлыкның рәсми сайтында һәм Республика порталында урнаштырыла:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Министрлыкның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык вазыйфаи затының, дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза):

документ формасында кәгазьдә чыганактагы форма буенча (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);

Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла);

б) гамәлгә кую документларының күчермәләре;

в) мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ (Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта күрсәтелә). Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ белешмәләре дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан оешма күрсәтә торган хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һәм башкалар) теркәлергә мөмкин.

Әгәр мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт төре буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче затлар реестрына кертелгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган өстәмә документларны тапшыру таләп ителми.

2.6.3. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза һәм документлар, шулай ук, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә туры китереп, Республика порталы аша имзаланган (расланган) электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин.

Гариза Республика порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең гади электрон имзасы белән имзалана.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (документларның электрон рәвешләре), шул исәптән ышаныч кәгазьләре pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларындагы файллар рәвешендә җибәрелә.

Электрон документларның (электрон документ рәвешләренең) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә уку һәм документ реквизитларын тану мөмкинлеген бирергә тиеш.

2.6.5. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

Министрлык тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында оешманың хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэмин итүчеләр реестрында булмавын раслый торган документлар, мөрәҗәгать итүче документлар тапшыра торган айның беренче көненә тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү буенча мөрәҗәгать итүче турында социаль хезмәтләрне күрсәтә торган тәэминатчылар реестрында язу теркәү фактын раслый торган документлар соратыла.

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

-әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган җыелмасы тапшырылганда;

гариза һәм 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру (гаризаны электрон формада тапшырган очракта).

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри юридик белеменең, тиешле өлкәдәге эш тәҗрибәсенең) булмавы, кирәкле квалификациягә ия затларның җитәрлек санда булмавы;

в) бәяләмә бирү елыннан алда килгән ике ел эчендә оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүгә бәйле рәвештәге гамәлләренә (гамәл кылмавына һәм (яки) карарларына карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп бүтән дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булуы;

г) оешма турындагы мәгълүматның ачык һәм аннан файдалана алу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булган очракта) туры килмәве;

д) бәяләмә бирелгән елга кадәрге ике ел эчендә 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы;

е) дөрес булмаган белешмәләр булган документларны яки тиешенчә рәсмиләштерелгән документларны тапшыру.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

2.11.1. Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, теркәү гарызнамә (гариза) һәм документлар кергән көнне башкарыла. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.2. Гаризаны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Республика порталындагы шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган бүлмәләрдә күрсәтелә.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

2.12.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) бүлмәләргә каршылыксыз үтеп керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

2) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында, шул исәптән объект хезмәткәрләре ярдәме белән дә, бүлмәләр буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

3) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

4) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итә алу үзлеге бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

5) инвалидларның хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ

рәвешен һәм аны биру тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, озата йөри торган этне кертү;

7) хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.12.3. Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Республика порталында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

гаризаны һәм документларны электрон документлар рәвешендә Республика порталы аша тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталында шәхси кабинет аша дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) Документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;

2) Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу вакытының саклануы;

3) Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;

4) мөрәҗәгать итүченең Бүлек белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза белән документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша

җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

Мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә багланышка керү озынлыгы – 15 минуттан артык түгел.

Мөрәҗәгать итүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә хокуклы.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта аша мөрәҗәгать иткәндә консультация бирелергә мөмкин.

2.14.3. Дәүләт хезмәте КФҮ күрсәтелми.

2.14.4. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликатын бирү гамәлгә ашырылмый.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча юллау административ процедурасын тасвирлау

Мөрәҗәгать итүченең гаризасын профиль буенча җибәрү гамәлгә ашырылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама.

3.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хаталарны төзәтү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта, шулай ук Республика порталы ярдәмендә (шул исәптән электрон) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән рәсми мөрәҗәгатьнең формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча да. Кирәк булганда Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать

иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, консультация күрсәтү (мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү) турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында язу теркәү.

3.6. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы зат аша Министрлык документларын үтәүне контрольдә тоту бүлегенә, почта, электрон почта, Республика порталы аша гариза бирә ала.

Гариза почта аша заказлы юллама итеп җибәрелергә мөмкин.

Электрон формада җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана (раслана) һәм, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы электрон чаралар һәм (яки) мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып тапшырыла.

Почта аша заказлы почта юлламасы яки электрон форма рәвешендә тапшырылган гариза гомуми тәртиптә карала.

3.6.1.1. Бүлек белгече тапшырылган документларның комплектлылыгын әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерә.

3.6.1.2. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яки ышанычлы заты аша мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кайтарып бирә. Таләп буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче рәсми мөрәҗәгатьне һәм документларны почта аша (электрон почтадан) җибәргән очракта, Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша (электрон почтадан) җибәрә.

3.6.1.3. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, гаризаны һәм документларны Министрлыкның Эшчәнлек күрсәтмәсендә билгеләнгән тәртиптә терки һәм, карап тикшерү өчен, Бүлеккә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон формалы гариза Бүлеккә электрон почта буенча яисә Интернет-кабул итү системасы аша җибәрелә.

Әлеге Регламентның 3.6.1.1-3.6.1.3 пунктларында билгеләнә торган процедуралар документлар Министрлыкка кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза һәм документлар.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Республика порталы аша электрон формада кабул итү.

3.6.2.1. Гаризаны электрон формада тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

авторизация уза;

электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза рәвешендә тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Формалаштырылган гаризаны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: электрон багланышлар системасы аша Министрлыкка җибәрелгән электрон эш.

3.7. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә белешмәләр алу өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.6 процедурасы тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тиешле органнарга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.7.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек эшендә катнаша торган органнар әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар яки мәгълүматның булмавы турында белдерүләр.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү.

3.8.1. Бүлек белгече түбәндәгеләр буенча тикшерү үткәрә:

документларны рәсмиләштерүнең дөреслеге буенча (тапшырылган документларның форма һәм эчтәлеге буенча билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә, документларда кирәкле имзаларның, мөһерләрнең, реквизитларның булуын тикшерә, чистартылган, төзәтелгән урыннар булмавын тикшерә);

бәяләнә торган хезмәт күрсәтүнең аның эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килүе буенча;

иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри юридик белеменең, тиешле өлкәдәге эш тәҗрибәсенең) булуы, кирәкле квалификациягә ия затларның җитәрлек санда булуы буенча;

Бәяләмә бирү турында гариза тапшырылган елга кадәрге ике ел эчендә 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булмавы;

бәяләмә бирү турында гариза тапшырыла торган елга кадәр ике ел эчендә оешманың аның ул күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләргә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контрольлек, компетенцияләренә туры китереп, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булмавы буенча;

оешма турындагы мәгълүматның ачык һәм аннан файдалана алу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә (алар булган очракта) туры килүе буенча;

Кагыйдәләрнең 2 нче кушымтасына ярашлы форма буенча теркәлә торган хат һәм бәяләмә проектларын яисә, әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән очракларда, әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына ярашлы формашы буенча бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты әзерли;

документларның әзерләнгән проектларын министрга кул кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән соң 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатын билгеләнгән критерийлар буенча бәяләү, министрга кул куюга юнәлдерелгән документларның проектлары.

3.8.2. Министр бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән теркәлгән хатны имзалый һәм аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.8.1 пунктының 1 пунктчасында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган теркәлә торган хат, бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.9.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итә.

Процедураны үтәү, техник мөмкинлек булган очракта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура министр теркәлә торган хатка кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат системаларында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү.

3.9.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.9.2.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе артыннан Министрлыкка мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлек белгече бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта буенча, электрон адреска, факс буенча) тапшыруны (җибәрүне) гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризада бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерүне почта буенча (электрон адреска, факс буенча) тапшыру ысулы турында күрсәтелгән очракта – бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне;

гаризада бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерүне шәхсән тапшыру ысулы турында күрсәтелгән очракта – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырылган (җибәрелгән) бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерү.

3.9.2.2. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвеше мөрәҗәгать итүчегә автомат рәвештә шәхси кабинетка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар дәүләт хезмәте күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документ Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны үтәү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуны) раслый торган документны Республика порталын кулланып җибәрү (бирү).

3.10. Техник хаталарны төзәтү.

3.10.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

ирекле формада төзелгән техник хатаны төзәтү турында гариза;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак

тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә дә) яисә Республика порталы аша җибәрелә.

3.10.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документлар Министрлыкка алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.10.3. Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү максатларында Бүлек белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны һәм аңа теркәп тапшырылган документларны карый;

теркәлә торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектлары әзерли;

документларның әзерләнгән проектларын министрга кул куюөчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.10.2 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән, министрга кул кую өчен җибәрелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерү белән теркәлә торган хат.

3.10.4. Министр үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән теркәлгән хатны имзалый һәм аларны Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.10.3 пунктында каралган процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән, министр имзалаган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерү белән теркәлә торган хат.

3.10.5. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар министр теркәлә торган хатка кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү.

3.10.6. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән

ысул белән (шәхсән, почта, электрон адрес, факс буенча) яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне тапшыруны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерүне почта буенча (электрон адреска, факс буенча) тапшыру ысулы турында күрсәтелгән очракта – үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне;

техник хатаны төзәтү турындагы гаризада үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турындагы нигезле белдерүне шәхсән тапшыру ысулы турында күрсәтелгән очракта – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яисә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәтен башкаруга таләпләрне билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм үтәлешен, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшерүне гамәлгә ашыру тәртибе.

4.1.1. Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.1.2. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм ешлыгы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуына контроль тәртибе һәм формалары.

4.2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең Министрлыктагы вазыйфаи затларның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшнең алып барылышына, шул исәптән документларны кабул итү

вакытларының һәм тәртибенең үтәлешенә;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүенә.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органдагы вазыйфаи затларның дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүгә, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан да, контроль тәртибенә һәм формаларына карата таләпләрне сыйфатлый торган нигезләмәләр.

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты, дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле министр тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүматны таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан, Республика порталыннан файдаланып җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул итеп алынырга мөмкин.

Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 көн эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш көн эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

5.6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы икенче көннән соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән

файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрына

________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

кемнән

________________________________________
оешма атамасы

________________________________________
адрес (почта һәм (яки) электрон)

________________________________________
телефон номеры (булган очракта)

ГАРИЗА

Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатының туры килүе турында бәяләмә бирүегез турында сорыйм

____________________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциясез оешма атамасы)

иҗтимагый файдалы хезмәтләр

____________________________________________________________________________
(иҗтимагый файдалы хезмәт атамасы)

аларны күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерийларга.

Оешманың чит ил агенты функцияләрен башкара торган коммерциясез оешма булып тормавы һәм бер ел һәм аннан күбрәк вакыт дәвамында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларын раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карарында расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килә торган, аталган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүен раслыйбыз:

________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтнең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында анык эчтәлегенә (күләменә, срокларына, күрсәтү сыйфатына) карата билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау);

________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри юридик белеменең, тиешле өлкәдәге эш тәҗрибәсенең) булуы, мондый затларның тиешле санда булуын раслау)

________________________________________

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрдән файдаланучы затларның аларны күрсәтү сыйфатыннан канәгать калуын раслау (бәяләмә бирелә торган елдан алдагы 2 ел эчендә оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүгә бәйле оешма гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп, башка органнар тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булмавы)

________________________________________

(коммерциясез оешма турында мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын раслау)

________________________________________

(оешманың бәяләмә бирелгән елдан алда килгән 2 ел дәвамында «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавын раслау)

## Раслый торган документлар теркәлә:

1. ________________________________
2. ________________________________
3. ________________________________

________________________________________

вазыйфа имза фамилиясе, исеме һәм ата исеме (булган очракта)

«___»____________20__ел.

Мөһер урыны (булган очракта)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәт сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта:

______________________________________________________________________
(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәвенә алу номеры)

______________________________________________________________________

түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр:

______________________________________________________________________.
(иҗтимагый файдалы хезмәтләр атамасы)

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең билгеләнгән критерийларына түбәндәге нигезләр буенча туры килми:

______________________________________________________________________.
(критерийларга туры килмәү нигезләре күрсәтелә)

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры

_______________/__________________________________________
имзасы фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)

«___»____________20__ел.

Мөһер урыны (булган очракта)